**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**28 декабря 2020г.** **№ 51**

## Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына административ комиссия төзү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен тапшыру турында

2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр эшчәнлеген булдыру һәм оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына Биектау муниципаль районы территориясендә кылынган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау өчен административ комиссия төзү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен тапшырырга.
2. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына административ комиссия төзергә, аның рәисен, рәис урынбасарын, җаваплы секретарен һәм административ комиссия әгъзаларын билгеләп куярга, 2021 елның 15 гыйнварына кадәр эш регламентын расларга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында»: htt://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: https://vysokaya-gora.tatarstan.ru / бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтә буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин